**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

Кәрәкәшле ав.

№ 1 11 гыйнвар 2016 ел

**Кәрәкәшле авыл җирлегендә җирле**
**референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131 санлы Федераль законның 22, 56 маддәләренә ярашлы – «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законның 15 маддәсе, 2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында"гы 67-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсе, «Кәрәкәшле авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе, 2015 елның 19 декабрендәге Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үз-үзләренә салым салу турында нигезләмәне һәм гражданнарның үз-үзләренә салым салу чараларын җыю һәм куллану тәртибен раслау турында»гы 16 санлы карары нигезендә, Кәрәкәшле авыл җирлеге советы карар итте:

1. Кәрәкәшле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2016 елның 28 февраленә билгеләргә.

2. Референдумга түбәндәге сорауларны чыгарырга (әйе/юк):

"Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә 2016 елда Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 120 (йөз егерме) сум күләмендә җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен бер тапкыр түләүләр кертергә ризамы:

1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү:

- Урал бистәсендәге күперне ремонтлау-104640 сум».

3. Җирле референдум үткәрү белән бәйле чыгымнарны Кәрәкәшле авыл җирлеге бюджеты акчалары хисабына тормышка ашырырга.

4. Әлеге карарны:

4.1 «Ютазы таны» газетасында бастырып чыгарырга һәм Ютазы муниципаль районының рәсми интернет сайтында урнаштырырга.

4.2 рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгына карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев